**ГЛАВА ТАТАРСКО-ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с. Татарский Янтык,
ул.Магазинная, д 31 а.
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422634 Татар Янтыгы авылы,
Кибет урамы, 31 а нчы йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

---

№2 2019 нчы елның 13 нче июне

# КАРАР

Социаль юнәлешле иҗтимагый
янгын сүндерү берләшмәләренә
һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә
өстәмә ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон"ы нигезендә, «Ирекле янгын сагы турында» 06.05.2011 ел, № 100-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында ирекле янгын саклау турында» 01.08.2011 ел, № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегендә ирекле янгын сагы үсеше өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында:

1.Ирекле янгын командаларына һәм ирекле янгын дружиналарына түбәндәге ташламаларны һәм ярдәм чараларын бирергә:

янгыннарны сүндергәндә һәм гадәттән тыш режимдагы авария-коткару эшләрен үткәргәндә төп эш урыныннан ялга җибәрү буенча ташлама;

янгыннарны сүндергәндә һәм авария-коткару эшләрен башкарганда ирекле янгын сагы әгъзаларын гадәттән тыш режимда тукландыру белән тәэмин итү.

2.Ирекле янгын сүндерүчеләр эшчәнлеген матди һәм мораль яктан стимуллаштыру.

Янгыннарны профилактикалауда һәм (яки) сүндерүдә һәм авария-коткару эшләрен үткәрүдә түләүсез нигездә катнаша торган ирекле янгын сүндерүчеләрне мораль һәм матди стимуллаштыруның түбәндәге чараларын билгеләргә:

ә.) муниципаль берәмлек башлыгының рәхмәт белдерүе;

б.) кыйммәтле бүләкләр тапшыру

в.) муниципаль берәмлек башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләү;

г.) Мактау Китабына кертү.

Предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре үз акчалары хисабына ирекле янгын сагы җәмәгать берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр бирә ала.

3.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагымда калдырам.

**Татар Янтыгы авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **Р. М. Шәмеев**